РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 57 2018 елның 19 декабре

**Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын гавами тыңлауларда хупларга һәм фикер алышуга чыгарырга (1нче кушымта).

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2019 елның 11 гыйнварында 15 сәгать 30 минутта Советлар йортының кече залында Төзүчеләр проспекты, 12нче йорт адресы буенча үткәрергә.

3. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (2нче кушымта).

4. Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетына Түбән Кама шәһәр Советы эшчәнлеген оештыру бүлеге белән берлектә:

4.1. әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) урнаштырырга;

4.2. әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында бастырырга»;

4.3. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24нче номерлы карары (басма матбугатта - «Ленинская правда» газетасының 2006 елның 10

ноябрендәге 220-221 (8572-8573) номерларында басылган) белән расланган, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, гавами тыңлаулар үткәрүне, гавами тыңлауларда катнашу өчен гражданнар һәм вазыйфаи затлардан кергән тәкъдимнәрне һәм гаризаларны кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э. Р. Долотказинага йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2018 елның 19 декабрендәге
57нче номерлы карарына
1нче кушымта

ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ
КАРАР ПРОЕКТЫ

№ 20__ елның «__» _______

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 маддәләре нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17нче номерлы карары (2017 елның 24 гыйнварындагы 3нче номерлы, 2018 елның 16 маендагы 21нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Карар кушымтасының 1 пунктның «а» пунктчасында, 8 пунктның «б» пунктчасында каралган өстәмәләр 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Карар кушымтасының 1 пунктның «б» пунктчасында, 5 пунктның «б» пунктчасында, 6 пунктның «б» пунктчасында, 7 пунктның «б» пунктчасында, 8 пунктның «в» пунктчасында каралган үзгәрешләр 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Түбән Кама шәһәре Мэрына (А.Р.Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен үткәрүгә җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2018 елның __ декабрендәге
_____номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. **«Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 маддәсендә**:

а) 1 пунктның 5 пунктчасында «шәһәр торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын саклауны» сүзләреннән соң «юл хәрәкәтен оештыру» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктның 20 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

оительным кодексом Российской Федерации».

в) 1 пунктның 22 пунктчасында:

«шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары» сүзләреннән соң «җирлек» сүзен «шәһәр» сүзе белән алмаштырырга»;

«,шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының (алга таба – планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә) билгеләнгән параметрларына туры килүе турында һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә, шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве турында һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә кабул ителгән үз белдеге белән төзегән бинаны сүтү турында карар, үз белдеге белән төзегән бинаны сүтү яки җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларына туры китерү, территорияне планлаштыру документлары, яки федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән тәңгәлләштерү турында карарлар (алга таба – билгеләнгән таләпләр белән тәңгәлләштерү), максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу, үз белдеге белән төзегән биналарны сүтүне яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру турында карарлар нигезендә кабул ителгән, шәһәр территориясендә урнашкан индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объекты, шәһәр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын

төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килү яисә туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрү,» сүзләрен өстәргә.

2. **«Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү хокукы» 7 маддәсендә** 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча белән тулыландырырга:

«16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.».

**3. «Шәһәрнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы» 8 маддәсендә** 2 пунктта «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзе белән алмаштырырга.

**4. «Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар»ның 16 маддәсендә** 2 пунктта:

а) беренче абзацта «яки шәһәр Мэры» сүзләрен «, шәһәр Мэры яки шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «шәһәр Мэры» сүзләрен «, шәһәр Мэры яки шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

5. **«Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүчене алыштыручы башка зат статусы» 32 маддәсендә** 6 пунктның 1 пунктчасында:

а) «сәяси партия» сүзләреннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә,»;

б) «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) «федераль законнарда каралган очраклар һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очраклар» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашу; муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү яки оешмага нигез салу вәкаләтләрен шәһәр исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, шәһәр нигез салучы (акционер, катнашучы) булып торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында шәһәр мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

6. **«Шәһәр Мэры статусы» 45 маддәсендә** 3 пунктның 1 пунктчасында:

а) «сәяси партия» сүзләреннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә,»;

б) «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) «федераль законнарда каралган очраклар һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очраклар» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашу; муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү яки оешмага нигез салу вәкаләтләрен шәһәр исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, шәһәр нигез салучы (акционер, катнашучы) булып торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында шәһәр мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

**7. «Шәһәр Мэры урынбасарлары» 47 маддәсендә** 8 пунктның 1 пунктчасында:

а) «сәяси партия» сүзләреннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә,»;

б) «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) «федераль законнарда каралган очраклар һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очраклар» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашу; муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү яки оешмага нигез салу вәкаләтләрен шәһәр исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, шәһәр нигез салучы (акционер, катнашучы) булып торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында шәһәр мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

8. **«Шәһәр Башкарма комитеты вәкаләтләре» 51 маддәсендә:**

а) 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.12, 3.13, 3.14 пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.12. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, күрсәтелгән объектларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикаларына, проект документларына таләпләренә куелган техник регламент таләпләре нигезендә биналарны, корылмаларны техник торышы һәм тиешле техник хезмәт күрсәтү предметына карап тикшерә, карап тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирә;

3.13. шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килүе турында һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә, шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына туры килмәве турында һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, шәһәр территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә, төзелгән яки

реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектларының яки бакча йортларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрә;

3.14. Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзегән бинаны сүтү, үз белдеге белән төзегән бинаны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләр белән тәңгәлләштерү турында карар, Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган яки максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, үз белдеге белән төзегән бинаны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләр белән тәңгәлләштерүне гамәлгә ашыра;»;

б) 4 пунктның 4.6 пунктчасында «шәһәр торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын саклауны» сүзләреннән соң «юл хәрәкәтен оештыру» сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктның 6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;».

**9. «Шәһәр Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар» 96 маддәсендә** 3 пунктта «җирле үзидарә органнары структурасы,» сүзләреннән соң «шәһәр Советы депутатларының санлы составы,» сүзләрен өстәргә.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина

Түбән Кама шәһәр Советының
2018 елның 19 декабрендәге
57нче номерлы карарына
2нче кушымта

# ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12нче йорт (Советлар йорты бинасы) 202 нче кабинет адресы яки 42-42-66 факсы буенча теркәлгән үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язмача Түбән Кама шәһәр Советына кертелә:

| т/с | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12нче йорт шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулар» тамгасы белән), шулай ук 42-42-66 факсы буенча.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә тапшырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина